Аллаһы турында хакыйкать (1 өлеш).

«Изге Язмаларның хак тәгълиматлары» дигән китапның беренче бүлегенә нигезләнгән материал (www.jw.org тан табып була).

ЙӨКЛӘМӘ. Үзеңне тикшереп чык. Син нәрсәгә иман итәсең һәм ни өчен? Изге Язмалардагы тәгълиматларны җентекләп карап чык. Башкаларга үзең иман иткәнне ничек аңлатып бирер идең?



АЛЛАҺЫ БЕЗНЕҢ ГАЗАПЛАРЫБЫЗГА ВАЕМСЫЗ КАЛАМЫ?

1 СИН НӘРСӘГӘ ИМАН ИТӘСЕҢ? ТИКШЕРҮ ҮТКӘР

Синеңчә, кешеләр сиңа нәрсә әйтә ала?

.....

.....

Син нәрсәгә иман итәсең?

.....

.....

Ни өчен син моңа иман итәсең?

.....

.....

www.jw.org © 2014 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania

2 ИЗГЕ ЯЗМАЛАРНЫҢ ТӘГЪЛИМАТЛАРЫН ТИКШЕР

Аллаһы һичкайчан явызлык кылмый, ул аны рөхсәт кенә итә.

(Мәкалә башында әйтелгән китапның 1 бүлеген, 6—8 абзацларны кара.)

Ягъкуб 1:13 ны укы.

Бу шигырь Аллаһы һичкайчан явызлык кылмый икәнен ничек исбатлый?

.....

.....

.....

Берәр нәрсәдә *гаепле булу* белән моны *рөхсәт итү* арасында нинди аерма бар? Нинди мисал китерерсең?

.....

.....

.....

Балалары тыңламаучан булып киткән әти кеше кебек, Йәһвә кешеләргә үз юллары белән барырга рөхсәт итә. Ләкин кешеләр үз тыңламаучанлыклары аркасында төрле авырлыкларга юлыгып тора һәм Йәһвә моңа гаепле түгел.

www.jw.org © 2014 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania

Аллаһы безне ярата һәм газапларыбызны күрү аңа авырту китерә.

(Мәкалә башында әйтелгән китапның 1 бүлеген, 11—13 абзацларны кара.)

Яратылыш 6:5, 6 ны укы.

Борынгы заманда җир йөзе явызлык белән тулгач, Йәһвә йөрәге сызланып күйган. Ни өчен без бүгенге явызлыкны күреп аның йөрәге бүген дә сызлана дип әйтә алабыз? **(ҖАВАП:** Малахий 3:6 ны укы.)

.....

.....

.....

1 Петер 5:7 не укы.

Синеңчә, ни өчен Йәһвә үз авырлыкларыбызны аңа сөйләп бирергә чакыра?

.....

.....

.....

Яратылыш 1:26 ны һәм 1 Яхъя 4:8 не укы.

Кешеләрнең газапларын күреп без борчылабыз икән, ни өчен без һич тә шикләнмичә, Йәһвә дә моны күреп борчыла дип әйтә алабыз?

.....

.....

.....

Авырлыкларыбызның чыганагы Йәһвә түгел, ул безне ярата һәм газапларны күрү аңа авырту китерә икәнен белү синдә нинди хисләр уята?

.....

.....

.....

www.jw.org © 2014 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania

3 НӘРСӘГӘ ИМАН ИТӘСЕҢ? АҢЛАТ

БЕРӘРСЕ БОЛАЙ ДИСӘ:

Аллаһы явызларны газапларга дучар итеп аларга җәза бирә.

СИН БОЛАЙ ДИП ҖАВАП БИРӘ АЛАСЫҢ:

Күп кенә диннәрдә шулай дип өйрәтәләр. Әмма мин ышанганча. . .

.....

.....

Син нинди шигырьне күрсәтерсең?

.....

Ни өчен нәкъ бу шигырьне?

.....

БЕРӘРСЕ БОЛАЙ ДИСӘ:

Аллаһы чиксез кодрәтле. Ул безне чыннан да яратса явызлыкка юл куймас иде.

СИН БОЛАЙ ДИП ҖАВАП БИРӘ АЛАСЫҢ:

Мин дә Аллаһы чиксез кодрәтле дип саныйм, әмма мин шулай ук ул безне чыннан да ярата дип саныйм, чөнки. . .

.....

.....

Син нинди шигырьне күрсәтерсең?

.....

Ни өчен нәкъ бу шигырьне?

.....

www.jw.org © 2014 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania